ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

## Татарстан Республикасы Гаилә кодексының 45 статьясына һәм «Мәгариф турында» Татарстан Республикасы Законының 14 статьясына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2023 елның 26 гыйнварында
кабул ителде

**1 статья**

Татарстан Республикасы Гаилә кодексының 45 статьясындагы $2^{1}$ өлешенә (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2009, № 1, № 12 (I өлеш); 2010, № 12 (II өлеш); 2011, № 9 (I өлеш); 2012, № 6 (I өлеш); 2013, № 5, № 7; 2014, № 4, № 6 (II өлеш); 2015, № 7 (I өлеш), № 10 (I өлеш); 2016, № 5; Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2017, № 52 (I өлеш); 2018, № 22 (I өлеш), № 92 (I өлеш); 2019, № 60 (I өлеш); 2020, № 26 (I өлеш); 2021, № 36 (I өлеш), № 77 (I өлеш); 2022, № 83 (I өлеш); 2023, № 3 (I өлеш), аны түбәндәге редакциядә бәян итеп, үзгәреш кертергә:

«$2^{1}$. Бала, шул исәптән уллыкка (кызлыкка) алынган яисә гаиләдә опекада яисә попечительлектә булган, тәрбиягә алган гаиләне дә кертеп, абыйсы һәм (яисә) апасы (бертуган һәм атасы йә анасы башка булган, уллыкка (кызлыкка) алынган), опекуннары (попечительләре) бу баланың ата-анасы (законлы вәкилләре) булган балалар яисә ата-анасы (законлы вәкилләре) бу баланың опекуннары (попечительләре) булган балалар укый торган дәүләт яисә муниципаль мәгариф оешмаларына төп гомуми белем бирү программалары буенча белем алуга өстенлекле кабул ителү хокукына ия була, «Россия Федерациясендә мәгариф турында» 2012 елның 29 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль законның 67 статьясындагы 5 һәм 6 өлешләрендә каралган очраклар моңа керми.».

**2 статья**

«Мәгариф турында» 2013 елның 22 июлендәге 68-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 14 статьясындагы $2^{1}$ өлешенә (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2013, № 7; 2014, № 7; 2015, № 3, № 10 (I өлеш); Татарстан

Республикасы законнар җыелмасы, 2016, № 3 (I өлеш), № 40 (I өлеш); 2018, № 1 (I өлеш), № 54 (I өлеш); 2019, № 2 (I өлеш); 2020, № 1 (I өлеш), № 26 (I өлеш), № 57 (I өлеш); 2021, № 36 (I өлеш), № 77 (I өлеш), № 93 (I өлеш); 2022, № 24 (I өлеш), № 49 (I өлеш), № 77 (I өлеш), № 90 (I өлеш); 2023, № 3 (I өлеш), аны түбәндәге редакциядә бәян итеп, үзгәреш кертергә:

«$2^1$. Бала, шул исәптән уллыкка (кызлыкка) алынган яисә гаиләдә опекада яисә попечительлектә булган, тәрбиягә алган гаиләне дә кертеп, абыйсы һәм (яисә) апасы (бертуган һәм атасы йә анасы башка булган, уллыкка (кызлыкка) алынган), опекуннары (попечительләре) бу баланың ата-анасы (законлы вәкилләре) булган балалар яисә ата-анасы (законлы вәкилләре) бу баланың опекуннары (попечительләре) булган балалар укый торган дәүләт яисә муниципаль мәгариф оешмаларына төп гомуми белем бирү программалары буенча белем алуга өстенлекле кабул ителү хокукына ия була, Федераль законның 67 статьясындагы 5 һәм 6 өлешләрендә каралган очраклар моңа керми.».

**3 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән соң 10 көн узгач үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты — Р.Н. Миңнеханов

Казан , Кремль
2023 ел, 03 февраль
№ 3-ТРЗ